ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**06.03.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 581**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 17 июлендәге 1876 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү шартлары турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 12 сентябрендәге 766 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 17 июлендәге 1876 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче, 2 нче кушымталар нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Учреждение җитәкчеләренә үзләренең локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.
4. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль район Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru ) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 06 мартындагы
581 номерлы карары
1 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмә.

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## II. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләренең база окладларын Билгеләү

2.1. . Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база оклады күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | 22 663 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Оештыручы педагог- | 22 758 |
| | Тренер-укытучы | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-психолог | 22 858 |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Структура бүлекчә җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе структур бүлекчә мөдире (начальнигы) һәм башка структура бүлекчәләре | 23 008 |

| | | |
|---|---|---|
| | мөдире (башлыгы) | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган аерымланган структура бүлекчә мөдире (башлыгы) | 23 058; |

2.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Айлык база оклады күләме, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 2 |
| "Урта звено мәдәният, сәнгать, һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 22 820 |
| "Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Тавыш операторы | 23 320; |
| Бизәүче рәссам- | |

2.3. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда медицина хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база оклады күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| "Урта медицина һәм фармацевтика персоналы" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 23 121 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина хезмәткәре (ир-ат)) | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медицина хезмәткәре (ир-ат))* | 24 821 |
| "Табиблар һәм провизорлар" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация | 26 521 |

| | | |
|---|---|---|
| | дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | |
| --------------------------------<br>*Вазифа оешма буйсынуында өч һәм аннан артык шәфкать туташы (медицина хезмәткәре (ир-ат) булган очракта билгеләнә. | | |

2.4. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база оклады күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча кизү торучы | 21 200 |
| | I төркем инвалид спортчыга ярдәм күрсәтеп йөрүче | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы | 21 200 |
| | Әйдәп баручы спортчы | |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Адаптацияли торган физик культура буенча инструктор методист | 22 063 |
| | Спорт инструкторы | |
| | Спортчы-инструктор | |
| | Атны йөрергә өйрәтүче тренер | |
| | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау буенча техник | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Күнекмәләр ясау барышы администраторы | 22 070 |
| | Адаптацияли торган физик культура буенча инструкторметодист | |
| | Адаптацияли торган физик культура буенча укытучы | |

| | | |
|---|---|---|
| | тренер<br>Хореограф | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Адаптацияли торган физик культура буенча өлкән инструктор-методист<br>Адаптацияли торган физик культура буенча өлкән укытучы тренер | 22 076 |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Аналитик (спорт төре яки төрләренең төркеме буенча) | 22 133 |

VIII бүлекнең 28 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"28 нче таблица

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар җитәкчеләренең башкарган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр һәм база окладлары күләме

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Күләм күрсәткеченең зурлыгы (агымдагы елның 1 сентябренә карата дәүләт биреме нигезендә шөгыльләнүчеләр укучыла саны), кеше <*> | База оклады, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимул бирү характерындагы түләүләр, |
|---|---|---|---|
| 1 | 0 - 200 | 30 000 | 4 000 |
| 2 | 201 - 400 | 32 000 | 5 000 |
| 3 | 401 - 700 | 36 000 | 5 000 |
| 4 | 701 - 1 200 | 37 000 | 6 000 |
| 5 | 1 201 - 1 800 | 40 000 | 7 000 |
| 6 | 1 801 һәм аннан югарырак | 42 000 | 8 000 |

--------------------------------
<*> Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмада (спорт-җайлаштыру мәктәбе) укучылар контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 06 мартындагы
581 номерлы карары
2 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы» нигезләмә.

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

II. Зеленодольск муниципаль районыының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмаларда эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Зеленодольск муниципаль районының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмаларындагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айлык база оклады күләме, сумнарда |
|---|---|
| "Беренче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 398 |
| "Икенче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 539 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 713 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 21 891 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 22 422 |

2.2. Зеленодольск муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айлык база окладлары күләме, сумнарда |
|---|---|
| "Беренче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 398 |
| "Икенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 539 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 713 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 21 891 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 22 118 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 22 304 |
| "Өченче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 22 494 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 22 687 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 22 884 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 23 085 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 23 311 |
| "Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары " һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 24 223 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 24 423 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 623 |

2.3. Хезмәткәр вазыйфасының һәм һөнәренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары буенча һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе башкарма хакимият федераль органының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

2.4. Төп урыннан тыш башка урында, шулай ук эш вакыты тулы булмаган шартларда эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә я башкарылган эшләр күләменә карап гамәлгә ашырыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук төп урыннан тыш башка урында эшләү тәртибендә биләнә торган вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым билгеләнә